Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4-2**

Бәтке авылы 7 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2021 елның 7 июлендәге “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”305-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Бәтке авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 11 номерлы карарына (2014 елның 14 ноябрендәге 12 номерлы, 2015 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2017 елның 22 августындагы 9-1 номерлы, 2019 елның 13 июнендәге 5-1 номерлы, 2020 елның 5 февралендәге 2-1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында “, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен аталган жир кишәрлекләре” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка житкерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның салым чорындагы җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлекне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов